КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 март г.Казань № 361

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинетының кайбер актлары үз көчен
югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Федоровский картлар һәм инвалидлар махсус интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе төзү турында» 2012 ел, 4 июнь, 477 нче карарының 5 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Зеленодольск муниципаль районындагы «Родник» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен оештыру турында» 2012 ел, 27 ноябрь, 1028 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чистай муниципаль районындагы «Салават күпере» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен оештыру турында» 2012 ел, 27 ноябрь, 1038 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Чистай муниципаль районындагы «Балкыш» халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең комплексы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен, аңарга «Чистай муниципаль районындагы «Салават күпере» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең территориаль үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен кушу рәвешендә, үзгәртеп оештыру турында» 2015 ел, 25 декабрь, 981 нче карарының 6 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы «Рәхәт» халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең комплексы

үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен, аңарга «Зеленодольск муниципаль районындагы «Чишмә» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең территориаль үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен кушу рәвешендә, үзгәртеп оештыру турында» 2016 ел, 22 гыйнвар, 34 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин